КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 декабрь г.Казань № 1259

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланыны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чаралары турында» 2020 ел, 21 май, 412 нче карары белән расланган Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт ста-ционар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланыны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын

йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланун ы, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чаралары турында» 2020 ел, 21 май, 412 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 13 июль, 582 нче; 2020 ел, 1 сентябрь, 771 нче; 2020 ел, 30 октябрь, 974 нче; 2020 ел, 8 декабрь, 1103 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1246 нчф; 2021 ел, 11 август, 706 нчы; 2021 ел, 9 ноябрь, 1059 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланууны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибенә, 2 пунктның икенче абзацында «2021 елның 17 ноябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 13 декабренә кадәр» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин